**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Олы Мәңгәр авыл җирлеге**
**Советы**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Совет Большеменгерского сельского поселения**

422756, Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8
тел. 3-46-24, факс 3-46-25

422756, Атнинский муниципальный район
с.Большой Менгер, ул. Советская, 8
тел. 3-46-24, факс 3-46-25

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» ноябрь 2022 ел. № 3

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2022 елның 29 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитеты;

- гражданнар җыенын үткәрү вакыты 29 ноябрь 2022 ел 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны — Иске Мәңгәр авылы, Тукай урамы, 11 йорт, Иске Мәңгәр авыл клубы;

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 22 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Иске Мәңгәр торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Иске Мәңгәр торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә,

кәндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгы буенча беренчел чараларны тәэмин итү («Ак урдэк»чишмәсен ремонтлау, чистарту һәм киртәләү);
2) Иске Мәңгәр авылының урам юлларын каплау һәм ремонтлау (вак таш сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
3) Урам яктырту хезмәте (яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау, лампаларны алыштыру) һәм яктырткычлар сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълумат-телекоммуникация челтәрендә тубәндаге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Иске Мәңгәр авылы, Тукай урамы, 11 йорт буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ф.Филатова